**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 19 март № 150

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 660 нчы; 2006 ел, 19 июнь, 312 нче; 2010 ел, 31 май, 419 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 26 октябрь, 890 нчы; 2011 ел, 23 декабрь, 1060 нчы; 2012 ел, 2 июнь, 466 нчы; 2012 ел, 10 октябрь, 846 нчы; 2013 ел, 19 март, 185 нче; 2013 ел, 4 декабрь, 955 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 4 июнь, 376 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль даими йөртүләр маршрутлары буенча даими йөртүләрнең дәүләт заказчысы вазыйфаларын башкара, дәүләт контракты төзи, дәүләт контракты шартлары үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра һәм даими йөртүләр маршруты карталарын бирә;»;

уникенче – унбишенче, кырык бишенче – кырык сигезенче, илленче – илле өченче, алтмыш икенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

кырык тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципальара даими йөртүләр маршрутлары реестрларын алып бару тәртибен, муниципальара даими йөртүләр маршрутларын билгеләү, үзгәртү, бетерү

тәртибен раслый, муниципальара даими йөртүләр маршрутлары реестрын алып бара, муниципальара даими йөртүләр маршрутларын билгели, үзгәртә, бетерә;»;

түбәндәге эчтәлекле яңа сиксән сигезенче – туксан бишенче абзацлар өстәргә:

«үз вәкаләтләре кысаларында даими йөртүләрне планлаштыру документын эшли һәм тормышка ашыра;

муниципальара даими йөртүләр маршруты буенча йөртүләрне гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурсны оештыручы вазыйфаларын башкара, ачык конкурста катнашуга гаризалар критерийләрен бәяләү өчен шкаланы билгели, йөртүчеләргә муниципальара даими йөртүләр маршрутлары буенча йөртүләрне гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими йөртүләр маршруты карталарын бирә, аларның эшчәнлеген тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, аларны төбәкара һәм муниципальара даими йөртүләр маршрутлары буенча башлангыч һәм (яки) соңгы тукталыш сыйфатында файдалану рөхсәт ителгән тукталыш пунктларын билгели;

Татарстан Республикасы территориясендә даими йөртүләр өчен файдаланыла торган транспорт чараларының экологик характеристикаларын билгели һәм раслый;

федераль законнарда каралган очракларда заказ буенча төбәкара пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы җирлекләре территорияләрендә пассажирларны утырту һәм төшерү урыннарын килештерү тәртибен билгели;

җирле үзидарә органнары тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы чикләрендә төнге вакытта парковкалар урнашу урыннарын билгели;

даими йөртүләрне оештыру һәм аларны гамәлгә ашыруны тикшерүдә тоту мәсьәләләре буенча федераль башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итә;

федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары белән аның компетенциясенә кертелгән бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

4.1 пунктның егерме өченче абзацы көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                   И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\150.docx